ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“02” сентябрь 2019 ел Әҗмәкәй авылы №2

**“2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында”**

Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге халкының «2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

## КАРАР БИРӘМ:

1. «2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2019 елның 02 сентябрь да соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Билгеләргә
3.1 үткәрү вакытын – **2019 елның 09 сентябрендә 14.00 сәгатьтә**;
3.2 үткәрү срогын – 1 көн;
3.3 үткәрү урынын – Тукай районы, Әҗмәкәй авылы, Үзәк урамы, 1 йорт (Мәдәният йорты);
3.4 фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресы – Тукай районы, Әҗмәкәй авылы, Үзәк урамы, 1 йорт (Мәдәният йорты); (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатька кадәр);
3.5 чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 2019 елның 09 сентябренә кадәр (тел.37-85-02).
4. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2019 елның 1 яртыеллык өчен Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Р. Г. Төхбәтуллин